# Алмашлыкларны сөйләмдә куллану

# Белемнәрегезне тикшерегез!

- ***Татар теленең морфология бүлеге нәрсәләрне өйрәнә?***
- ***Сез нинди сүз төркемнәрен беләсез?***
- ***Исем сүз төркеме турында ниләр беләсез?***
- ***Алмашлык сүз төркеме турында ниләр беләсез?***

Күп нокталар урынына тиешле зат алмашлыкларын куеп күчереп языгыз.

1.Укып чыгып, дөнья тануны,
Бәхетебезне эзләп табуны
Зур ышаныч белән көткәнсез,
... иң сабыр кеше икәнсез.
2. ... кем дип сорыйсызмы?
Күмәч пешерүчеләр ... .
Кешеләрнең йөзләренә
Шатлык өләшүчеләр ... .

Зат алмашлыкларын I һәм I I I затка куеп, күчереп языгыз.

***Син куанганда куанып, син кайгырганда кайгырып, синең белән бергә сулап, бергә көлеп яшәүче кем? Әниең!***
 ***Син авырганда, төннәр буе сине юатучы, күз карашы белән иркәләүче кем соң? Әниең!***
  ***Иртә белән сине: “Тор, соңга каласың, уятырга кызгандым, бик тәмле йоклый идең”,- дип иркәләп уятучы, мәктәпкә озатучы кем соң ул? Әниең ич!***
***Әниләр шундый әйбәт кешеләр инде алар.***

Сорау алмашлыкларын табыгыз:

*Әллә нәрсә булды минем*
*Әти белән әнигә,*
*Йөдәтәләр сорау биреп:*
*“Ник?” тә, “нәрсәгә?”, “нигә?”*
*-Ник икеле алдың?-диләр.*
*-Нигә соңга калдың?-диләр.*
*-Ник дәресең карамадың?*
*-Белмәгәч, ник сорамадың?*
*-Ник тагын пычракка кердең?*
*-Нигә дип су ерып йөрдең?*
*-Ник сугыштың Салих белән?-*
*Әйтерсең инде мин беләм.*

(Р.Вәлиев)

Сорау алмашлыкларын табыгыз:

*Әллә нәрсә булды минем*
*Әти белән әнигә,*
*Йөдәтәләр сорау биреп:*
*“Ник?” тә, “нәрсәгә?”, “нигә?”*
*-Ник икеле алдың?-диләр.*
*-Нигә соңга калдың?-диләр.*
*-Ник дәресең карамадың?*
*-Белмәгәч, ник сорамадың?*
*-Ник тагын пычракка кердең?*
*-Нигә дип су ерып йөрдең?*
*-Ник сугыштың Салих белән?-*
*Әйтерсең инде мин беләм.*

(Р.Вәлиев)